МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.11.2018 г. Казань № под-1737/18

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турында» 2018 елның 03 июлендәге 541 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында б о е р а м:

1. Конкурс нигезендә сайланып «Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» грантын алу турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.,

2. Гомуми белем бирү идарәсенә (Т.Т. Федорова):

әлеге боерыкны өч көн эчендә дәүләт теркәвенә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшырырга;

Нигезләмә нигезендә грант алуга конкурста сайлап алуны оештырырга һәм уздырырга.

3. Нигезләмә нигезендә «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесен (Л.Н. Ногманова) грант алуга конкурс нигезендә сайлап алу операторы итеп билгеләргә.

4. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г.К. Мөхәммәткәримова) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган тәртиптә Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына каралган чаралар кысаларында грант түләү буенча эшне оештырырга.

5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары И.Г. Хәдиуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр урынбасары - министр Р.Т.Бурганов

Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгы боерыгы
белән расланган
дата № -

Конкурс нигезендә сайланып «Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» грантын алу турында нигезләмә

## 1. Төп нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» (алга таба – конкурс сайлап алауы, грант) грантын алуга конкурс нигезендә сайлап алуны оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

1.2. Грантка дәгъва кылучы, Грант бирүче, Грант алучы грантта катнашучылар булып торалар.

Грантка дәгъва кылучы – Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, конкурста сайлап алуда катнашучы белем бирү оешмасы.

Грант бирүче – грантлар бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба - Министрлык).

Грант алучы – Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыручы, конкурс сайлап алуында җиңүче дип танылган белем бирү оешмасы.

1.3. Грант конкурс сайлап алуы нәтиҗәләре буенча бирелә.

Грант – федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль фәннәрне тирәнтен өйрәнүле төп гомуми, урта гомуми белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру, шулай ук педагогик коллективның һөнәри үсеше һәм квалификациясен күтәрү һәм педагогик хезмәткәрләрне матди кызыксындыру өчен акчалата бүләк буларак Грант алучыга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү.

1.4. Грант алуга конкурс сайлап алуында җиңүче дип табылган белем бирү оешмасы грантының күләме 150 221,9 мең сум тәшкил итә.

1.5. Конкурс сайлап алуы критерийлары:

| № п/п | Критерийлар | Баллар |
|---|---|---|
| 1 | Белем бирү оешмасының конкурс үткәрүгә кадәр ике ел дәвамында эшчәнлек күрсәткечләре: | 1 нче күрсәткеч буенча барлыгы 40 баллдан да артык түгел |
| 1.1 | Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профильләр кысаларында аерым уку предметларын, предмет өлкәләрен тирәнтен өйрәнүне тәэмин итә торган белем бирү программалары булу өлешендә (профильле укыту) һөнәрне үзләштерүгә әзерлек нигезләре буларак укучы шәхесен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру: | 1.1 нче күрсәткеч буенча барлыгы 20 баллдан да артык түгел |
| | предметларны (математика, физика, химия, биология, информатика, технология) өйрәнүнең тирәнтен (профильле) дәрәҗәсе | бирелгән предметлар буенча сәгатьләр саны уку планының гомуми күләменнән 50% һәм аннан да күбрәк булганда - 5 балл, 50% тан кимрәк булганда - 0 балл тәшкил итә |
| | укучыларның ихтыяҗларын һәм кызыксынуларын исәпкә алып, эчтәлекне дифференциацияләүгә нигезләнгән һәм эшчәнлек планының гомуми күләменең 75 проценты күләмендә математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль аерым уку предметларын тирәнтен өйрәнүне тәэмин итә торган һәр укучыга кимендә 10 сәгать күләмендә дәрестән тыш эшчәнлек планы | бирелгән планның булуы - 5 балл; булмавы - 0 балл |
| | (спорт-савыктыру, рухи-әхлакый, социаль, гомуминтеллектуаль, гомуммәдәни) юнәлешне үз эченә алган дәрестән тыш эшчәнлек планы | дәрестән тыш эшчәнлекнең барлык юнәлешләре булу - 5 балл;<br>булмау - 0 балл |
| | укучылар тарафыннан социаль тәҗрибәне үзләштерүгә, үз һөнәри эшчәнлекләренең юнәлешен сайлап алуга әзерлекләрен формалаштыруга, белемнәрне, фикер сөрешен, сәламәт һәм имин яшәү рәвеше нормаларын формалаштыруга һәм үстерүгә юнәлдерелгән, белем бирү оешмасы укучылары арасында социологик тикшеренүләр нәтиҗәләре белән расланган укучыларны тәрбияләү һәм социальләштерү программалары | программаның булуы – 1 дән 5 баллга кадәр, булмавы - 0 балл |

| | | |
|---|---|---|
| 1.2 | Конкурс үткәрелү елы алдыннан килгән елның 30 декабренә урта гомуми белем бирү программасы буенча дәүләт йомгак аттестациясе (БДИ) күрсәткечләре | 1.2 күрсәткече буенча 10 баллдан да артык түгел |
| | мәҗбүри предметлар буенча (рус теле һәм математика (профиль дәрәҗәсе)) | республиканың уртача БДИ нәтиҗәләре күрсәткечләрен 10 баллга һәм аннан да күбрәк арттырганда – 5 балл; арттырмаганда – 0 балл |
| | тирәнтен (профильле) өйрәнелә торган предметлар буенча (физика, химия, биология, информатика) | республиканың уртача БДИ нәтиҗәләре күрсәткечләрен 15 баллга һәм аннан да күбрәк арттырганда – 5 балл; арттырмаганда – 0 балл |
| 1.3 | Конкурс үткәрелү елы алдыннан килгән елның 30 декабренә төп гомуми һәм урта гомуми белемнең белем бирү программалары буенча дәүләт йомгак аттестациясе нәтиҗәләре: | 1.3 күрсәткече буенча 10 баллдан да артык түгел |
| | ТДИ нәтиҗәләре буенча канәгатьләнерлек билгеләр булмау (мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы билгеләгән төп гомуми белем бирүнең белем бирү программасын үзләштерүне раслый торган балларның минималь санынннан түбәнрәк) | Канәгатьләнердерми торган билгеләре булган укучыларның булмавы – 5 балл; Канәгатьләнердерми торган билгеләре булган укучыларның булуы – 0 балл |
| | БДИ нәтиҗәләре буенча канәгатьләнерлек билгеләр булмау (мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы билгеләгән төп гомуми белем бирүнең белем бирү программасын үзләштерүне раслый торган балларның минималь санынннан түбәнрәк) | Канәгатьләнердерми торган билгеләре булган укучыларның булмавы – 5 балл; Канәгатьләнердерми торган билгеләре булган укучыларның булуы – 0 балл |
| 2 | Аерым предметлар, башка интеллектуаль конкурслар һәм төрле дәрәҗәдәге ярышлар буенча Бөтенроссия олимпиадасында укучыларның катнашуы нәтиҗәләре | 2 нче күрсәткеч буенча 5 баллдан да артык түгел |

| | | |
|---|---|---|
| | конкурс үткәрелү елы алдыннан килгән елның 30 декабренә кадәр торышы буенча исемлеге һәм дәрәҗәләре башкарма хакимиятнең чираттагы уку елына мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм норматив-хокукый көйләү функцияләрен башкаручы федераль орган тарафыннан расланган Бөтенроссия олимпиадасының аерым предметлар буенча муниципаль, республика, төбәк һәм йомгаклау этапларында, мәктәп укучылары олимпиадасының халыкара этапларында җиңүчеләр һәм призер булган укучылар, WorldSkills Russia милли чемпионаты һәм WorldSkills юниорлары саны төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү оешмасына кертелгән укучыларның гомуми санынннан кимендә 50 процент өлешен тәшкил итә | 5 балл – критерийга туры килә,<br>0 балл – туры килми |
| 3. | Конкурс үткәрелү елы алдыннан килгән елның 30 декабренә торышы буенча математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профильләр предметларын тирәнтен өйрәнү белән төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын практик гамәлгә ашыру нәтиҗәләренә фараз күрсәткечләре: | 3 нче күрсәткеч буенча барлыгы 10 баллдан да артык түгел |
| 3.1 | Конкурс үткәрелү елы алдыннан килгән елның 30 декабренә торышы буенча «Россиянең иң яхшы топ-500 мәктәбе» рейтингында булу | 5 баллов – мәгариф оешмасы «Россиянең иң яхшы топ-500 мәктәбе» рейтингына кертелгән<br>0 балл – мәгариф оешмасы «Россиянең иң яхшы топ-500 мәктәбе» рейтингына кертелмәгән |
| 3.2 | югары белем бирү оешмаларына яисә һөнәри белем бирү оешмаларына әзерлек яисә белгечлек юнәлешләренә кергән, чыгарылыш сыйныфның (урта гомуми белем бирү уку-укыту программасының) профиленә туры килә торган һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның өлеше, югары белем бирү оешмаларына яисә һөнәри белем бирү оешмаларына кергән гомуми санның гомуми саныннан конкурс үткәрүгә кадәр елның чыгарылыш сыйныф укучыларының гомуми саныннан кимендә 75 процентын тәшкил итә, шул ук вакытта уңай динамика 2 процент тәшкил итә. | 5 балл — критерийга туры килә,<br>0 балл – туры килми |

## 2. Конкурста сайлап алуда катнашуга гариза бирү

2.1. Грант бирүче, гаризаларны теркәү башланганчы унбиш көннән дә соңга калмыйча, боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Грант бирүченең рәсми сайтында (алга таба - Министрлык сайты) урнаштыру юлы белән конкурс сайлап алуы турында игълан итә.

2.2. Грантка дәгъва кылучыга Башкарма комитетның мәгариф идарәсе муниципаль органы (бүлеге) җитәкчесе белән килештерелгән гаризаны, әлеге нигезләмәнең 2.4 пунктында күрсәтелгән документларны «Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» грантының республика конкурс комиссиясенә (алга таба - республика конкурс комиссиясе) 420011, Казан шәһ., Кремль ур., 9 йорт, 2 кат, 207 нче каб. (9-00 дән 17-00 гә кадәр, төшке аш 12-00 дән 13-00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе - ял көннәре) агымдагы елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча тапшырырга кирәк.

2.3. Гариза агымдагы елның 15 гыйнварыннан соң бирелгән очракта грантка дәгъва кылучы конкурс сайлап алуында катнашу хокукыннан мәхрүм ителә

Әлеге Нигезләмә таләпләреннән тайпылып әзерләнгән яисә тулы күләмдә тәкъдим ителмәгән конкурс материаллары дәгъва кылучыга кире кайтарыла, гариза теркәлмәячәк.

2.4. Конкурс сайлап алуында катнашу өчен белем бирү оешмасы җитәкчесе имзасы белән түбәндәге документларны (1 нче кушымтаны) тапшырырга кирәк.:

конкурс сайлап алуында катнашу нияте турында язма мөрәҗәгатьне үз эченә алган гариза (2 нче кушымта);

гамәлгә кую документларының күчермәләре;

федераль законнар нигезендә бирелгән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия күчермәсе;

белем бирү оешмасында белем алучыларның яшәү өчен интернат булуын раслый торган мәгълүмат белешмәсе һәм документлар (күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә, хокук билгели торган документларның күчермәләре);

интернатта яшәүче укучыларның санын раслый торган документ;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары алдында срогы чыккан бурыч булмауны раслый торган документ;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә; әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән Грантка дәгъва кылучы эшчәнлеге күрсәткечләренең нәтиҗәлелеген һәм үтәлешен раслый торган документлар;

тапшырылган грантны гамәлгә ашыру кысаларында грант тапшырылуның барлык срогы (календарь ел) дәвамында чаралар, чараларның сроклары турында мәгълүматны үз эченә алган конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга гариза концепциясе (А4 форматының 10 битеннән дә ким булмаган һәм 30 биттән артмаган күләмдә) (3 нче кушымта нигезендә);

гаризаны имзалаучы затларның вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләре (җитәкчесе, баш бухгалтер).

Документларны кабул итеп алганла грантка дәгъва кылучыга теркәлү номеры бирелә.

## 3. Конкурс сайлап алуын оештыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Грант бирүгә конкурс сайлап алуы агымдагы елның 15 гыйнварыннан 15 февраленә кадәр үткәрелә. Конкурс ике этапта үткәрелә:

конкурс сайлап алуында катнашуга гаризалар салынган конвертларны ачу, агымдагы елның 15 гыйнварында «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә 14.00 сәгатьтә Казан ш., Зур Кызыл ур., 68 адресы буенча узачак. Гаризалар салынган конвертларны ачканда һәм 4 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелгән документларга техник экспертиза нәтиҗәләре нигезендә конкурс сайлап алуында катнашучылар игълан ителәчәк;

гаризаларны карау (агымдагы елның 16 гыйнварыннан 28 гыйнварына кадәр), аның барышында республика конкурс комиссиясе түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

агымдагы елның 21 гыйнварына кадәр – Конкурс документлары таләпләренә туры килүгә гаризаларны карау һәм конкурста катнашуга рөхсәт бирү турында Карар кабул итә яки 1-3 кушымталарының әлеге Нигезләмәгә туры килмәвенә һәм (яки) билгеләнгән формаларга туры килмәвенә бәйле рәвештә гаризаны кире кага;

агымдагы елның 28 гыйнварына кадәр – конкурс материалларын бәяләү һәм анализлау.

3.2. Грант бирү өчен конкурс республика конкурс комиссиясе тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә әлеге Нигезләмәнең 1 нче бүлегендә билгеләнгән конкурс сайлап алуы критерийлары нигезендә баллар бирү юлы белән үткәрелә

Һәр критерий буенча баллар саны 5 баллы (0 дән 5 кә кадәр) шкала буенча республика конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Грантка дәгъва кылучы документларына экспертиза нәтиҗәләре буенча эксперт бәяләмәсе төзелә, аны республика конкурс комиссиясе рәисе һәм экспертиза үткәргән затлар имзалый.

Конкурс нәтиҗәләре нигезендә республика конкурс комиссиясе грант бирүгә дәгъва кылучыларның рейтинг исемлеген төзи.

Конкурс сайлап алуында җиңүче дип рейтингта беренче урын алган Грантка дәгъва кылучы танылa.

Республика конкурс комиссиясенең эш нәтиҗәләре дәгъва кылучыларның рейтинг исемлеге булган кушымта беркетелгән беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Бер үк санда балл җыйган һәм беренче позицияне алган дәгъва кылучылар булганда, республика конкурс комиссиясе мәгариф оешмалары эшчәнлегенә өстәмә анализ оештыра.

Кабат экспертиза нәтиҗәләре эксперт бәяләмәсендә һәм республика конкурс комиссиясе беркетмәсендә чагыла. Республика конкурс комиссиясе беркетмәсе нигезендә дәгъва кылучылар рейтингына тиешле үзгәрешләр кертелә

3.3. Конкурс сайлап алуының барлык материаллары Министрлыкның рәсми сайтында түбәндәге бүлектә урнаштырыла: программалар һәм проектлар / бүлекчә: Укытучыларга грантлар/«Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм».

3.4. Конкурс материалларын бәяләү өчен комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм 13 кешедән торган комиссия әгъзалары составында республика конкурс комиссиясе төзелә.

3.5. Республика конкурс комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

3.6. Конкурста катнашучы мәгариф оешмалары җитәкчеләре һәм педагоглары республика конкурс комиссиясенең әгъзалары була алмыйлар.

3.7. Республика конкурс комиссиясе утырышлары кирәк булганда уздырыла һәм, әгәр анда аның составының яртысыннан артыгы катнашса, карар чыгарырга хокуклы дип санала.

3.8. Эш йомгаклары буенча республика конкурс комиссиясе агымдагы елның 1 февраленә кадәр конкурс сайлап алуында җиңүчене билгели.

Грант бирү өчен конкурс нәтиҗәләре дәгъва кылучыларга 2 эш көне эчендә «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениесенең рәсми сайты аша ирештерелә.

3.9. Республика конкурс комиссиясе карары белән килешмәгән очракта дәгъва кылучы республика конкурс комиссиясе рәисе исеменә язма рәвештә Грантка дәгъва кылучылар исемлеге бастырылганнан соң 2 эш көне эчендә шикаять бирергә хокуклы.

3.10. Республика конкурс комиссиясе апелляцияне 5 эш көне дәвамында карый. Апелляция буенча республика конкурс комиссиясе карары республика конкурс комиссиясенең исемлек составыннан гади күпчелеге тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез очракта республика конкурс комиссиясе рәисе хәлиткеч тавыш бирергә хокуклы. Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча республика конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен чыгара:

- апелляцияне канәгатьләндерү һәм конкурс нәтиҗәләрен үзгәртү турында;
- апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәрешсез саклап калу турында.

3.11. Конкурс сайлап алуында җиңүче Министрлык боерыгы белән раслана. Конкурсның сайлап алу нәтиҗәләре Министрлык сайтында Программа һәм проектлар бүлеге/Укытучыларга грантлар/«Математик, табигый-фәнни һәм

мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» бүлекчәсендә урнаштырыла

3.12. Белем бирү оешмасы турында дөрес булмаган, тулы булмаган яки ялган белешмәләрне ачыклаганда грант бирү турында карар кабул ителми.

## 4. Конкурсны финанслау

Грант бирү максатларында субсидияләр бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

«Математик, табигый-фәнни һәм
мәгълүмати-технологик профиль
предметлар тирәнтен өйрәнелә
торган төп гомуми, урта гомуми
белем бирү программаларын
гамәлгә ашыручы мәгариф
оешмаларына ярдәм» гранты
турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Теркәү номеры: _
Гаризаны теркәү датасы:_

«Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» грантын бирү буенча республика конкурс комиссиясенә дәгъва кылучы тарафыннан тапшырылган документлар
ИСЕМЛЕГЕ

| № | Документ исеме/ конкурс материалы | Битләр саны |
|---|---|---|
| 1. | гариза | |
| 2. | гамәлгә кую документларының күчермәләре | |
| 3. | федераль законнар нигезендә бирелгән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия күчермәсе | |
| 4. | белем бирү оешмасында яшәү өчен интернат булуын раслый торган мәгълүмати белешмә һәм документлар (күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә, хокук билгеләүче документларның күчермәләре) | |
| 5. | интернатта яшәүче укучылар санын раслый торган документ | |
| 6. | Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары алдында срогы чыккан бурыч булмауны раслый торган документ | |
| 7. | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | |
| 8. | әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән Грантка дәгъва кылучы эшчәнлеге күрсәткечләренең нәтиҗәлелеген һәм үтәлешен раслый торган документлар (соңгы 2 елда) | |
| 9. | тапшырылган грантны гамәлгә ашыру кысаларында грант тапшырылуның барлык срогы (календарь ел) дәвамында чаралар, чараларның сроклары турында мәгълүматны үз эченә алган конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга гариза концепциясе | |

| | | |
|---|---|---|
| 10. | гаризаны имзалаучы затларның вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләре (җитәкчесе, баш бухгалтер). | |



Барлыгы ____ ____ бит

Тапшырды (Ф.И.О., вазифа, эш урыны): ____________________________________________
__________________________________________________

Имза: _________________________________ Дата: ___________________________________ _

Кабул итте (Ф.И.О., вазифа, эш урыны): ___________________________________________

Имза: _________ _________________ _ Дата

«Математик, табигый-фәнни һәм
мәгълүмати-технологик профиль
предметлар тирәнтен өйрәнелә
торган төп гомуми, урта гомуми
белем бирү программаларын
гамәлгә ашыручы мәгариф
оешмаларына ярдәм» гранты
турында Нигезләмәгә
2 нче кушымта

Теркәү номеры: _
Гаризаны теркәү датасы:_

Конкурс сайлап алуында катнашу өчен
гариза

| Мөрәҗәгать юллаучы (учредитель) | Җитәкченең ФИОсы (тулысынча) | Мөрәҗәгать юллаучының юридик адресы, телефон, электрон адрес | Концепция (проект) исеме |
|---|---|---|---|
| | | | |

Кушымта (документлар исемлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында бирелгән), битләр санын күрсәтеп.

Мөрәҗәгать юллаучы оешма җитәкчесе имзасы: ______________________

М.П.

Дәгъва кылучыны грантка тәкъдим итү органының утырыш протоколы номеры һәм датасы: _____ ____ ______ _ _____ _ ________ ___

*Документлар беркетелгән гариза тегелгән һәм номерланган, мәгариф оешмасы җитәкчесенең мөһере белән беркетелгән булырга тиеш.*
*Күрсәтелгән адрес буенча ябыштырылган конвертта кәгазь рәвештә тәкъдим ителә.*

«Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» гранты турында Нигезләмәгә
3 нче кушымта

Теркәү номеры: _
Гаризаны теркәү датасы:_

Конкурс сайлап алуында катнашуга гариза концепциясе

1. Чараның тасвирламасы:

1.1. «Мәктәп - ВУЗ» интеграциясе шартларында челтәр проектларын булдыру һәм гамәлгә ашыру аша укыту һәм тәрбия эчтәлеген һәм технологияләрен камилләштерү буенча инновацион эшчәнлек программаларын гамәлгә ашыру чараларының максат һәм бурычлары, тәҗрибәсе һәм перспективаларының гомуми тасвирламасы.

1.2. Чараларны тормышка ашыру буенча эшләр комплексы тасвирламасы:

1.2.1. Инновацион эшчәнлек программасын сайлап алуның нигезе.

1.2.2. Проектны гамщлгә ашыру кысаларында эшләр составы.

1.2.3. Төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы, математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметларны тирәнтен өйрәнә торган мәгариф оешмасының инновацион эшчәнлеге программасы.

1.2.4. Белем бирү оешмасында инновация эшчәнлеге программаларын гамәлгә ашыру буенча консультация һәм методик ярдәм күрсәтүче экспертларның квалификация дәрәҗәсе һәм күрсәтелгән экспертларның ярдәм күрсәтүгә ризалыгы (язмача рәвештә).

1.2.5. Чараның турыдан-туры нәтиҗә күрсәткечләренә минималь таләпләр:

1) мәгариф оешмасында математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметларны тирәнтен өйрәнүле төп гомуми, урта гомуми белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру буенча инновация эшчәнлегенең норматив-хокукый һәм оештыру-методик базасын булдыру,

2) белем бирү оешмаларының – инновацион эшчәнлектән файда күрүчеләрнең төрле максатчан төркемнәре өчен укыту семинарлары (вебинарлар) үткәрү;

3) максатчан күрсәткечкә (индикаторга) ирешү турында хисап: предметара технологияләр буенча укыту методикасын үзләштергән һәм аларны математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметларны тирәнтен өйрәнүле төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланучы белем бирүче укытучылар өлеше, узган елларда квалификацияләрен күтәргән укытучыларны исәпкә алып, ел саен кимендә 25 % дәрәҗәсендә.

1.2.6. Татарстан Республикасы мәгариф системасында математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль фәннәр тирәнтен өйрәнүле белем бирү процессын оештыруның нәтиҗәле технологияләрен һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларының эчтәлеген тарату максатында методик челтәрләр төзү һәм үстерү модельләрен, шул исәптән «Мәктәп-ВУЗ» интеграциясе шартларында презентацияләү (тасвирлау).

1.3. Төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы, математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметларны тирәнтен өйрәнә торган мәгариф оешмасының инновацион эшчәнлек программасы эшләрен башкару план-графигы.

| Календарь ел | Чаралар исемлеге | Чараны башкару срогы (периоды) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |
| | | |
| | | |

2. Агымдагы календарь елында чараны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә грант бирү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләренең планлаштырылган кыйммәтләре:

предметара технологияләр буенча укыту методикасын кулланып математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметларны тирәнтен өйрәнүле төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланучы белем бирүче укытучылар өлеше, узган елларда квалификацияләрен күтәргән укытучыларны исәпкә алып, ел саен кимендә 25 % дәрәҗәсендә.

3. Статистик мәгълүмат.

3.1. Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында укучылар саны.

3.2. Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасындагы укытучылар саны (квалификацион категориясен, булган очракта гыйльми дәрәҗәсен күрсәтеп).

3.3. Өстәмә мәгълүмат.

3.3.1. Белем бирү оешмасында муниципаль (региональ, федераль) инновацион мәйданчык сыйфатында инновацион эшчәнлек тәҗрибәсе булу, шулай ук төп гомуми, урта гомуми белемнең математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметларны тирәнтен өйрәнүгә нигезләнгән белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда төп норматив һәм хокукый документлар нигезендә технологияләрне модернизацияләүгә һәм тәрбияне тотуга методик ярдәмнең нәтиҗәле эшен оештыру,

3.3.2. Белем бирү оешмасында төп гомуми, урта гомуми белемнең математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметларны тирәнтен өйрәнүле белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда инновацион эшчәнлекне җайга сала һәм регламентлый торган локаль актлар системасы булу.

3.3.3. Белем бирү оешмасында идарәчел карарлар кабул итү практикасы булу, шул исәптән, шул исәптән дәүләт йомгаклау аттестациясенә (бердәм дәүләт имтиханы, төп дәүләт имтиханы), илкүләм мәгариф сыйфатын тикшерүләргә, россиякүләм тикшерү эшләренә, шулай ук математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль фәннәрне тирәнтен өйрәнүле төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда белем бирү казанышларының сыйфатын бәйсез бәяләүгә таянып.

«Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» гранты турында Нигезләмәгә
4 нче кушымта

Теркәү номеры: _
Гаризаны теркәү датасы:_

« Математик, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик профиль предметлар тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм » грантын бирү буенча республика конкурс комиссиясенә дәгъва кылучы тарафыннан тапшырылган документларга техник экспертиза
БӘЯЛӘМӘСЕ

| № | Документ исеме/ конкурс материалы | Кабул ителгән (Әйе) | Кабул ителмәгән (юк) |
|---|---|---|---|
| 1. | гариза | | |
| 2, | гамәлгә кую документларының күчермәләре | | |
| 3. | федераль законнар нигезендә бирелгән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия күчермәсе | | |
| 4. | белем бирү оешмасында яшәү өчен интернат булуын раслый торган мәгълүмати белешмә һәм документлар (күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә, хокук билгеләүче документларның күчермәләре) | | |
| 5. | интернатта яшәүче укучылар санын раслый торган документ | | |
| 6. | Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары алдында срогы чыккан бурыч булмауны раслый торган документ | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | | |
| 8. | әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән Грантка дәгъва кылучы эшчәнлеге күрсәткечләренең нәтиҗәлелеген һәм үтәлешен раслый торган документлар (соңгы 2 елда) | | |
| 9. | тапшырылган грантны гамәлгә ашыру кысаларында грант тапшырылуның барлык срогы (календарь ел) дәвамында чаралар, чараларның сроклары турында мәгълүматны үз эченә алган конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга гариза концепциясе | | |
| 10. | гаризаны имзалаучы затларның вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләре (җитәкчесе, баш бухгалтер). | | |

| Техник экспертиза нәтиҗәсе | |
|---|---|
| Техник экспертиза нәтиҗәләре буенча грант алуга рөхсәт ителә | Техник экспертиза нәтиҗәләре буенча грант алуга рөхсәт ителми |
| | |

Республика конкурс комиссиясе әгъзасы
(имза)

Дата ФИО